МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

Волгоградская ул., д. 47, г.Казань, 420044

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

Волгоград ур., 47 нче йорт, Казан шәһәре, 420044

тел. (843) 557-20-01, 557-21-02; факс 523-90-74. E-mail: mtsz@tatar.ru, www.mtsz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.10.2020 г.Казань № 3

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 26 октябрендә 6904 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 7 февралендәге 1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1040» саннарын «1029» саннарына алмаштырырга;

1 нче кушымтада:

1 пунктның 3, 4, 5 һәм 8 графаларында «14233», «946», «6,6», «310» саннарын тиешенчә итеп «13923», «903», «6,5», «302» саннары белән алмаштырырга;

45 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

51 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

62 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

123 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

273 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

274 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

2 нче кушымтада:

1 пунктның 3, 4, 6 һәм 8 графаларында «67792», «9684», «1067», «730» саннарын тиешенчә итеп «67448», «9612», «1061», «727» саннары белән алмаштырырга;

101 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

183 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

3 нче кушымтада:

1 пунктның 3, 4, 5, 6, 8, 11, 13, 16, 19 һәм 24 графаларында «39567», «3821», «9,7», «798», «185», «390», «14», «103», «72», «54» саннарын тиешенчә итеп «39387», «3753», «9,5», «795», «183», «384», «13», «101», «70», «53» саннары белән алмаштырырга;

80 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. «Яр Чаллы шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Әлмәт шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Аксубай районы Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Тәтеш районы Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе директорларына әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта әлеге карар кабул ителүгә бәйле рәвештә 2020 елга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен үзләренә билгеләнгән квоталар һәм (яки) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервка куела торган эш урыннары саны гамәлдән чыгарыла торган эш бирүчеләргә язмача рәвештә хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А. Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.А.Зарипова